ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында»**;

2) 1 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил**»;

б) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 статьяда:

а) 1 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзаларының, алар тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләре гамәлгә ашырылуга бәйле рәвештә)» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзалары, алар тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләре гамәлгә ашырылуга бәйле рәвештә)» сүзләрен өстәргә;

5) 5 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен карау кысаларында махсус рөхсәттән башка Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан сак астында тоту урыннарына һәм мәҗбүри эшләр, кулга алу, иректән мәхрүм итү рәвешендәге җинаять җәзаларын үтәтү учреждениеләренә Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы беренче – дүртенче өлешләрендә һәм $159^1$ – $159^3$, $159^5$, $159^6$, 160, 165 һәм 201 статьяларында каралган җинаятьләр, әгәр әлеге җинаятьләр индивидуаль эшкуар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм (яисә) аныкы булган, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдаланыла торган мөлкәт белән идарә итүгә бәйле рәвештә кылынган булса йә әлеге җинаятьләр коммерциячел оешманың идарә органы әгъзасы тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә йә коммерциячел оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген яисә башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кылынган булса, шулай ук Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы бишенче – җиденче өлешләрендә һәм 171, $171^1$, $171^3$ – $172^3$, $173^1$ – $174^1$, 176 – 178, 180, 181, 183, 185 – $185^4$ һәм 190 – $199^4$ статьяларында каралган җинаятьләр турындагы эшләр буенча шик белдерелә торган, гаепләнә торган һәм хөкем ителгән затлар хокукларын яклау максатларында кереп йөрергә;»;

8) 13 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9) 14 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 17-ТРЗ